РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ МЕШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422062, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.Лесхоз, ул. Кукморская, 2а
тел.(84362) 44-2-19

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422062, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Лесхоз бистәсе, Кукмара урамы, 2а йорт
тел. (84362) 44-2-19

e-mail: Mesh.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.10.2024

КАРАР
№ 19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 №31 карары белән кабул ителгән муниципаль берәмлек Уставын "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131 Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында 17.12.2021 елгы №33 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларын һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 06.03.2023 елның №10 карары белән расланган тәртиптә 2024 елның 4 декабрендә ачык тыңлаулар үткәрергә 10.00 сәгатьтә Лесхоз мәдәният йортының: ТР, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Детсодовская ур., 26 йорты адресы буенча.
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 4 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Советына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турындагы карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен бастырып чыгарырга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

- Татарстан Республикасы, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Детсадовская урамы, 26 нчы йорт;
- Татарстан Республикасы, Саба районы, Сабабаш авылы, Школьная урамы.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Мишә
авыл җирлеге Башлыгы А.Х.Гатиятуллин

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Мишә авыл
җирлеге Советы карары белән
25.10.2024 №19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21) пунктча өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

2.19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2. 34 статьяның 1 пунктындагы 26) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26) матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

3. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:
«12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;».

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Мишә авыл
җирлеге Советы карары белән
24.10.2024 №19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мишә авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422062, ТР, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Детсадовская ур., 26 йорт, язма рәвештә Мишә авыл җирлеге башлыгына.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 07.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында игълан ителгән яисә хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылган көннән алып кабул ителә.

2. Җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422062, ТР, Саба районы, Лесхоз бистәсе, Детсадовская ур., 26 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу»тамгасы белән).

Мишә авыл
җирлеге Башлыгы А.Х.Гатиятуллин